**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 17 май № 321

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау һәм «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 август, 624 нче карары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2015 ел, 11 июнь, 427 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау һәм «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 август, 624 нче карары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2015 ел, 11 июнь, 427 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемендә һәм 1 нче пунктында «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасы» сүзләрен «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибендә:

Тәртипнең исемендә «коммерциягә карамаган микрофинанс оешмасы» сүзләрен «коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе» сүзләренә алмаштырырга;

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрофинанс оешмасы исемен үзгәртү турында» 2016 ел, 5 май, 284 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын гамәлгә ашыру максатларында эшләнде һәм «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә (алга таба – Фонд) субсидия бирү механизмын билгели.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\321.doc